ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

05.02.2019 № 118

Нурлат муниципаль районының өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ гомуми белем бирү оешмалары укучыларын туклану белән тәэмин итү турында

Нурлат муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары укучыларын тулы сыйфатлы, балансланган туклану белән тәэмин итү, СанПиН 2.4.5.2409-08 таләпләрен үтәү һәм укучыларның аерым категорияләренә социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә чараларын гамәлгә ашыру максатларында

КАРАР БИРӘМ:

1. Нурлат муниципаль районының өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ гомуми белем бирү оешмалары укучылары өчен 2019 елда туклануны оештыру тәртибе турында нигезләмәне расларга.

2. Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеген 2019 елда әлеге максатларга Нурлат муниципаль районының җирле бюджетында каралган акчалар чикләрендә гомуми белем бирү оешмалары укучылары өчен ташламалы шартларда туклануны оештыруны гамәлгә ашыручы оешмаларга субсидияләр бирү буенча вәкаләтле органы итеп билгеләргә.

3. Нурлат муниципаль районы гомуми белем оешмалары җитәкчеләренә:

3.1. Гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларның төп туклыклы матдәләрне карап тоту буенча балансллы туклануны оештырырга, шулай ук өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ балаларның өйләренә барып гамәлдәге законнар нигезендә кайнар туклануны оештыруны хәл итүче тиешле оешма белән килешү төзү юлы белән туклану продуктлары җыелмасын бирергә.

3.2. Укучыларның туклануын Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 25 гынварындагы 15-р номерлы «Акча бүлеп бирү турында» боерыгында расланган бүлеп бирелгән финанс чараларыннан чыгып оештырырга.

4. Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) Нурлат, Аксубай районнарында территориаль бүлегенә гомуми белем бирү оешмаларында санитар-гигиена нормаларының үтәлешен контрольдә тотуны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

5. 2019 елның 1 гыйнварыннан гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тукландыруны оештыру өчен җаваплы мәгариф бүлегенә, укучыларга социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба – ЕГИССО(СТИБДМС)) куллану юлы белән, ЕГИССО(СТИБДМС) операторы тарафыннан билгеләнгән форматларга туры китереп, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә туклану бирү турында мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.

6.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге начальнигы урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Л.Н.Маняпов

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының
2019 ел, 5 февраль, 118 нче
карарына кушымта

Нурлат муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының социаль ярдәмгә мохтаҗ укучыларын 2019 елда тукландыруны оештыру тәртибе турында нигезләмә

1. Әлеге нигезләмә өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ 1-11 нче сыйныф укучылары өчен, шулай ук өйдә белем алучы (алга таба-укучылар) укучыларга бушлай туклану продуктлары җыелмасы бирү рәвешендә социаль ярдәм күрсәтү чараларын күрсәтү тәртибен билгели, шул исәптән:

- үз составында 4 һәм аннан да күбрәк балалы гаиләләрдән булган балаларга;

- аз керемле, җан башына уртача керем Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбән булган аз керемле гаилә балаларына;

- социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрдәге балаларга.

Әлеге категория укучылар өчен кайнар туклану Нурлат муниципаль районының җирле бюджеты акчалары хисабына 1-11 сыйныф укучылары өчен көнгә бер укучыга 15 сум күләмендә кайнар иртәнге аш яки төшке аш рәвешендә бирелә.

Өйдә укучы укучылар өчен азык-төлек җыелмасы айга бер тапкыр 20сеннән дә соңга калмыйча уку көннәре санын исәпләүдән көненә 15 сум күләмендә бирелә. Азык-төлек продуктлары җыелмасы гомуми белем бирү оешмасының боерыгы белән агымдагы елның 1 гыйнварына кадәр һәм агымдагы елның 1 сентябренә кадәр раслана.

2. Укучыларны туклandыруны оештыру өчен:

2.1. гомуми белем бирү оешмасында укучыларга социаль ярдәм күрсәтү буенча комиссия (алга таба - комиссия) төзелә, аның составы оешма директоры тарафыннан раслана. Комиссия составына укучыларның туклануын оештыру өчен җаваплы директор урынбасары, җәмәгать берләшмәләре вәкилләрен ата-аналарны (законлы вәкилләрне) кертергә тәкъдим ителә. Комиссия әгъзаларының гомуми саны биш кешедән дә ким булмаска тиеш.

Комиссия:

- сыйныф җитәкчеләреннән әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасындагы форма нигезендә социаль ярдәм чаралары бирү турында гаризалар кабул итә;

- Нурлат муниципаль районының матди ярдәм республика үзәгенең 33 нче бүлеге биргән гаризаларның ата - аналары тарафыннан тәкъдим ителгән социаль ярдәм чараларын алучылар турындагы мәгълүматны карый һәм социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында, яисә социаль ярдәм чараларын бирүдән баш тарту турында карар кабул итә;

- сыйныф җитәкчесе тәкъдиме белән социаль куркыныч хәлдә булган аз керемле гаиләләрне һәм аларның торак шартларын тикшерә, аларның матди хәлен билгели, социаль ярдәм чараларын күрсәтү яки социаль ярдәм чараларын бирүдән

баш тарту турында карар кабул итә, ул тикшерү нәтиҗәләре белән берләттән актта әлеге нигезләмәнең 1 нче кушымтасына ярашлы рәвештә теркәлә;

- укучыларның исемлекләрен елга ике тапкыр раслый: агымдагы елның 1 гыйнварына кадәр һәм агымдагы елның 1 сентябренә кадәр.

2.2. сыйныф җитәкчеләре:

- ата-аналардан (законлы вәкилләрдән), әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасындагы форма нигезендә социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында гаризаларны кабул итәләр;

- гариза алган көннән соң өч көн эчендә комиссия карамагына җибәрелә;

- комиссиягә ата-аналар комитетының аз керемле гаиләләрне һәм социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрне тикшерү, аларның торак шартларын тикшерү, социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында карар кабул итү яки социаль ярдәм чараларын бирүдән баш тарту максатыннан аларның матди хәлен билгеләү турындагы тәкъдимнәрен кертәләр;

- мәктәп буенча укучыларны туклandыруны оештыру өчен җаваплы директор урынбасарына һәр сыйныфларда балаларының фактик саны турында хәбәр итәләр.

2.3. ата-аналар яки аларны алыштыручы затлар:

- әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасы нигезендә сыйныф җитәкчеләренә социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында гаризалар җибәрә;

- кирәк булган очракта комиссия соравы буенча гаиләнең керем күләмен раслаучы документлар тапшыралар.

2.4. мәктәп буенча укучыларны туклandыруны оештыру өчен җаваплы директор урынбасары:

- мәктәп буенча укучыларның фактик санын исәпкә алып бара;

- ашханә мөдиренә яки кайнар туклануны оештыру белән шөгыльләнүче оештыручыга әлеге уку көненә ташламалы тукланырга тиешле укучылар саны турында хәбәр итә.

3. Гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчесе:

- гамәлдәге законнар нигезендә укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыруга төп туклыклы матдәләрне балансны карап тоту буенча җавап тота;

- Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор Идарәсе белән килештерелгән ассортимент исемлеге нигезендә буфет продукциясен сату өчен җаваплы;

- гамәлдәге законнар нигезендә өйдә укучы укучыларга азык-төлек продуктлары җыелмасын түләүсез бирүне оештыру өчен;

- Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының вәкаләтле органына социаль ярдәм чаралары күләмен исәпләү өчен укучылар реестрын дөрес һәм вакытында тапшыру өчен җавап тота.

4. Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының вәкаләтле органы:

- Нурлат муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары киселешендә укучылар реестрын кайнар туклануны оештыруны гамәлгә ашыручы оешмага раслый һәм җибәрә;

- Нурлат муниципаль районы территориясендә гомуми белем бирү оешмалары укучылары өчен ташламалы шартларда туклануны оештыру буенча хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны каплау максатларында, Нурлат муниципаль

районы Башкарма комитеты карары белән һәм тиешле килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда оешмаларга субсидияләр бирә;

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының ФБПна:

а) хисаптан соң килүче айның дүртенче числосына кадәр укучыларны тукландыру турында фактгагы мәгълүматлар;

б) Нурлат муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары киселешендә агымдагы елның 1 гыйнварына кадәр һәм агымдагы елның 1 сентябренә кадәр укучыларның реестрын тәкъдим итүне тәэмин итә.

5. Кайнар тукlануны оештыруны гамәлгә ашыручы оешма:

- Нурлат муниципаль районы территориясендә укучылар өчен гомуми белем бирү оешмаларында ташламалы шартларда кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру буенча хезмәт күрсәтә;

- Нурлат муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында өйдә укучы укучыларга бушлай туклану продуктлары җыелмасын кабул итү-тапшыру актын төзү буенча хезмәт күрсәтә.

6. Социаль ярдәм чараларын алучылар турында мәгълүмат Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге белән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек турында килешү нигезендә Нурлат муниципаль районы матди ярдәм республика үзәгенең 33 нче бүлеге тарафыннан тапшырыла.